**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КОМСОМОЛЕЦ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» июль 2019 ел №6/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 23 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милегендә булган муниципаль мөлкәт реестрын төзү һәм алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 13/2 санлы карарын гамәлдән чыгару турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 51 маддәсе 5 өлеше, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2011 елның 30 августындагы «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 424 номерлы приказы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 23 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милегендә булган муниципаль мөлкәт реестрын төзү һәм алып бару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 13/2 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе О.В. Сурова